ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» сентябрь 2022 ел № 213

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында «Гаилә архивын тапшыр» Республика конкурсының муниципаль этабы турында

Үсеп килүче буынны патриотик тәрбияләүгә ярдәм итү максатларында гаилә тарихы призмасы аша ил һәм туган як тарихын өйрәнү, туган як тарихы белән кызыксынуны саклау һәм үстерү, буыннар арасында гаилә кыйммәтләрен һәм багланышларын ныгытуда ярдәм итү, тарихи һәм туган якны өйрәнү әдәбиятын укуның архив материаллары белән эшләүгә җәлеп итү, Татарстан Республикасы Архив фондын кыйммәтле тарихи чыганаклар белән тулыландыру нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 10 февралендәге 24-од номерлы архив эше буенча боерыгы белән расланган “Гаилә архивын тапшыр” конкурсы турындагы нигезләмә нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның 23 сентябреннән 9 октябренә кадәр “Гаилә архивын тапшыр” Республика конкурсының муниципаль этабын оештырырга һәм уздырырга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында “Гаилә архивын тапшыр” Республика конкурсының муниципаль этабын уздыру өчен жюри функцияләре белән оештыру комитетының кушымтада бирелгән составын расларга.

3. Татарстан Республикасы архив эше буенча Дәүләт комитетының 10.02.2022 елның 24-од номерлы боерыгы белән расланган “Гаилә архивын тапшыр” конкурсы турындагы Нигезләмә нигезендә оештыру комитетына үз эшләрен оештырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының Архив бүлегенә конкурс уздыруны оештырырга һәм «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенә муниципаль этапта җиңүчеләрнең документлар пакетын 14.10.2022 елына кадәр җибәрергә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **Р.Р. Шәрипов**

Татарстан Республикасы
Әгерже муниципаль районы
Башкарма комитетының
23.09.2022 № 213
карары белән расланган

Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районында
“Гаилә архивын тапшыр” республика конкурсының муниципаль этабын уздыру
өчен жюри функцияләре булган оештыру комитеты составы

| | |
|---|---|
| Шәрипов Рөстәм Рәшит улы | Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары– рәис |
| Романова Марина Николаевна | Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге башлыгы - секретарь |
| Нурмөхәммәтова Чулпан Равил кызы | Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Башкарма комитетының социаль үсеш бүлеге башлыгы |
| Гайфуллина Гөлнара Марсель кызы | Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Башкарма комитетының ЗАГС бүлеге башлыгы |
| Сафиуллина Вәсилә Гарәфетдин кызы | Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының “Мәгариф идарәсе” МКУ башлыгы |
| Җәметова Гөлнас Фелис кызы | “Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Тарих һәм мәдәни мирас музее” МБМУ директоры |
| Абзалиева Дания Заһир кызы | “Татмедиа” АҖ филиалы “Әгерже хәбәрләре” («Агрызские вести") газетасы редакциясе җитәкчесе, баш мөхәррир (килешү буенча) |